ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«10 статья. **Республика укыту-методика берләшмәләре**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү системасында үз эшчәнлекләрен, Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән гомуми белем бирү һәм урта һөнәри белем бирү системасында укыту-методика берләшмәләре турындагы типлаштырылган нигезләмәләрне исәпкә алып, шушы орган раслаган нигезләмәләргә таянып башкаручы республика укыту-методика берләшмәләре төзелергә мөмкин.

2. Республика укыту-методика берләшмәләре составына ихтыярый башлангычларда педагог хезмәткәрләр, фәнни хезмәткәрләр һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм башка оешмаларның бүтән хезмәткәрләре, эш бирүчеләр һәм аларның берләшмәләре вәкилләре, федераль

дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкилләре керә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 апрель
№ 26-ТРЗ